Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенен Г.Ибраһимов исемен-дәге Тел, әдәбият һәм сәнгать инсти-тутынын комплекслы экспедициясе Ләмберә һәм Ромоданово районнары татар авылларында эшләде. Галимнәр безнен республика территориясендә ике атна иделәр – Ләмберә районнын биш һәм Ромодан районынын ике авылында – Белозерье белән Алтарда булдылар.

Халык ижаты бvлеге модире филология фәннәре кандидаты Ильмир Ильдар улы Ямалтдинов әйтvенчә, экспедиция составында милли мираснын торле аспектлары белән шогыльләнvче белгечләр - лингвистлар, фольклорчылар, музыка белгече, язма чыганакларны ойрәнvче археограф, халык һонәрләре белән кәсепләре буенча сәнгать белгече һәм хәтта борынгы язмаларны, шул исәптән кабер ташларында сурәтләнгәннәрне тикшерvче эпиграфист та бар.   Экспедиция составындагы галимнәр башта Ләмберә район vзәгендә иделәр, аннары Черемишево белән Пензятка авылларында татар халык авыз ижаты жимешләрен, конкvреш әйберләрен, тарихи истәлекләр материалларын жыйдылар.

– Халык мәдәнияте вәкилләре белән беренче очрашулар vз нәтижәләрен бирде инде, - ди Ильмир Ямалтдинов. - Черемишевода, мәсәлән, безгә жирле vзенчәлекләр белән милли стильдә башкарылган ботенләй аутентик чvкеп ясалган акчалар эләкте. Без халык жырын яздыра алдык, ул кvп буыннар дәвамында авыздан-авызга тапшырылып килә. Әлбәттә, язма чыганаклар белән эш кvпкә катлаулырак. Ләкин без эшне дәвам итәбез.

Әйтеп китәргә кирәк, 1957 елда Татарстан галимнәре Мордовиянен ботен территориясендә татар халкынын тормышын тикшергән иделәр. Шул исәптән этнографик экспедиция Ләмберә белән Ромоданово районнарында да булган. Ә бv-генге материаллар әлеге тикшеренvчеләр очен нигез булып хезмәт итәчәк.

Казан кунаклары, фольклор тикшеренv-ләренен икенче атнасында, Саранск шәһәре Мордовия хокvмәте каршындагы гуманитар фәннәр фәнни-тикшеренv институты (НИИ гуманитарных наук при Правительстве РМ) коллегалары тарафыннан оештырылган «Фольклор ландшафты бvген» («Фольклорный ландшафт сегодня») халыкара фәнни-гамәли конференциясендә катнаштылар. Казан галимнәре билгеләп vткәнчә,

Мордовия татарлары юмартлык һәм кунакчыллык белән аерылып торалар. Үз чиратында, Татарстан фольклор жыючылары, табышларнын бер олешен Саранск краеведлары белән уртаклашып, И.Д.Воронин исемендәге музейга (Республиканский музей им. И.Д.Воронина) Ләмберә осталары белән ойдә тукыган солгеләрне бvләк иттеләр. Моннан тыш, РМ Хокvмәте каршындагы гуманитар фәннәр фәнни-тикшеренv институты директоры Галина Куршева Казан коллегаларынын якташыбыз, танылган фольклорчы һәм музыкант Владимир Ромашкиннын фәнни тикшеренvләрен бастырып чыгаруда ярдәм итәргә тотынуларын хәбәр итте. Милли фольклор әсәрләренен текстлары һәм аларнын нота партитурасы фәнни олеш белән беррәттән басылып чыгачак. Жыентыкны быел ук чыгарырга ниятлиләр.
Үзенчәлекле фольклор материалын экспедиция галимнәре Ромоданово районы Белозерье, Алтар авыллары картларыннан язып алганнар. Андагы жирле vзенчәлекләр фән очен бик тә кызыклы.
Татарстан галимнәре эшләрен Ләмберә районы Аксён, Инят авылларында дәвам иттеләр.
Экспедициядә тупланган материаллар озак еллар дәвамында житди академик тикшеренvләр очен нигез булачак. Алар нигезендә фәнни мәкаләләр язылачак, ә алар vзләре фәнни басмада гомумиләштереләчәк.

Наилә НАСЫРОВА